ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРЖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерже шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www.agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» гыйнвар 2020 ел № 06

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларның туклануын оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (яңа редакциядә)

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 21 декабрендәге 523 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (яңа редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче пунктның икенче абзацында «25,50» санын «25,80» санына алмаштырырга;

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә;

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**